Татарстан Республикасы мәдәният министрлыгы

**Дәүләт бюджет оешмасы**
**"К.Тинчурин ис. Татар дәүләт драма һәм комедия театры"**

420015 ТР, Казан шәһәре, М.Горький ур., 13 йорт.
Тел./факс: 264-35-18
www.tinchurinteatr.ru
E-mail: karimkonkurs@mail.ru

Министерство культуры Республики Татарстан

**Государственное бюджетное учреждение**
**«Татарский государственный театр драмы и комедии им. К.Тинчурина»**

420015 РТ, г. Казань, ул. М.Горького, д.13.
Тел./факс: 264-35-18
www.tinchurinteatr.ru
E-mail: karimkonkurs@mail.ru

**02/1095 от 06.12.2023 г.**

**Министру образования и науки**
**Республики Татарстан**
**И.Г.Хадиуллину**

**Уважаемый Ильсур Гараевич!**

Татарский государственный театр драмы и комедии им. К.Тинчурина совместно с журналом «Идель» объявляют межрегиональный конкурс драматургии «Язга хәтле яз». Спектакль по пьесе победителя будет поставлен на сцене Тинчуринского театра в 2024 году.

Цель проекта – открытие новых имен в драматургии среди молодежи, создание новых произведений для татарского театра, воспитание молодых драматургов.

В конкурсе могут принять участие авторы в возрасте 18-35 лет (включительно). Для участия необходимо подать заявки до 15 декабря по адресам tinchurinteatr1933@gmail.com и Idel-kazan@mail.ru .

На конкурс принимаются оригинальные пьесы на татарском языке. Один автор может отправить как минимум 3 пьесы.

Порядок проведения конкурса:

– Образовательная программа – 20 декабря
– Прием готовых работ до 15 марта 2024 года
– Лонг-лист будет объявлен до 30 марта
– Шорт-лист станет известен до 15 апреля
– Награждение победителей будет 30 апреля 2024 года.

Победитель будет определен по результатам театральных читок. Спектакль по пьесе победителя будет поставлен на сцене Тинчуринского театра в 2024 году. Отрывки пьесы-победителя будут опубликованы в журнале «Идель».

С положением конкурса можно ознакомиться по https://idel-tat.ru/news/novosti-tt/iaslar-arasynda-iazga-xatle-iaz-tobakara-dramaturgiia-baigesenda-katnas-nigezlama .

Уважаемый Ильсур Гараевич, просим Вас проинформировать подведомственные структуры Министерства образования и науки республики в районах и городах Татарстана об этом проекте. Для желающих заявки на участие принимаются до 15 декабря.

Контакты для связи: 89503163021 (Алина).

Приложение: на 3 л. в 1 экз.

**С уважением,**
**директор,** **Ф.Н.Мусагитов**
**Заслуженный работник культуры РТ**

**КОНКУРС: «Язга хәтле яз» төбәкара драматургия бәйгесендә катнаш! (нигезләмә)**

***«Идел» журналы һәм К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры яшьләр арасында «Язга хәтле яз» дип аталган драматургия конкурсы игълан итә.***

## НИГЕЗЛӘМӘ

**1. Гомуми нигезләмә**
1.1 «Язга хәтле яз» драматургия бәйгесе К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры һәм «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел»-«Идель» журналы редакциясе» белән берлектә оештырыла;
1.2 Бәйгедә 18 яшьтән 35 яшькә кадәр (35 яшь тулганнарны да кертеп) булган авторлар катнаша;
**2. Максатлар һәм бурычлар**
2.1 Бәйгенең максаты – драматургиядә яшьләр арасында яңа исемнәрне ачу, шулай ук татар театры өчен яңа әсәрләр иҗат итү;
2.2 Бәйгенең бурычы – яшьләр арасында драматургларны үстерү, тәрбияләү; милли театрлар өчен репертуарга алырлык әсәрләр даирәсен киңәйтү; театрларны яңа пьесалар куюга стимуллаштыру;
**3. Оештыручылар**
3.1 К. Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры (Татарстан, Казан, Горький ур., 13, https://tinchurinteatr.ru/); һәм «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел»-«Идель» журналы редакциясе» (Татарстан, Казан, Декабристлар ур., 2, https://idel-tat.ru/ )
3.2 Бәйгене үткәрү белән оештыручылар төркеме шөгыльләнә.
**4. Авторларга таләпләр:**
4.1 Һәр катнашучы бәйгегә, күп дигәндә, 3 пьеса җибәрә ала;
4.2 Бәйгедә катнашу өчен ул үзе турында мәгълүмат җибәрергә тиеш: ФИО; туган көн; белем; һөнәр; кыскача биография; почта адресы (индекс белән), телефон номеры, электрон адрес, пьеса исеме һәм аның язылу датасы, номинация. Иҗади эшләр бары тик әлеге мәгълүмат булган очракта гына кабул ителә;
**5. Текстка карата таләпләр:**
5.1 Бәйгегә татар телендә язылган оригиналь пьесалар кабул ителә;
5.2 Пьеса, конкурс игълан ителгәнче, соңгы 2 елда яки конкурс барышында иҗат ителгән булырга тиеш. Пьесаның кайчан язылганын күрсәтү мәҗбүри;
5.3 Пьеса моңа кадәр профессиональ театрларда куелмаган һәм интернет-басмаларда чыкмаган булырга тиеш (авторның шәхси сайтында чыгуы хуплана);
5.4 Башка драматургия бәйгеләрендә катнашып җиңгән эшләр кабул ителми. Шулай ук текст башка физик яки юридик затның милке булмаска тиеш;

5.5 Иҗади эшләрне «MS Word» форматында («Times New Roman», 14 pt, 1,5 интервал) tinchurinteatr1933@gmail.com һәм Idel-kazan@mail.ru электрон адресларына җибәрергә кирәк (ZIP программасында архивлап җибәрү мөмкин). Пьесаның титул битенә номинация языла);
5.6 Пьеса аерым файлда «Idel_konkurs» дип исемләп җибәрелә;
5.7 Пьесаны «Язга хәтле яз» конкурсына тәкъдим итеп, шорт/лонг-листка кергән очракта, автор текстны алга таба театрда кую яки интернет-басмада чыгару мөмкинлеге белән килешә.
5.8 Бәйрәм сценарийлары, проза инсценировкалары кабул ителми;
5.9 Экстремизм, көч куллану һәм сәхнәгә яраклы булмаган лексикалы иҗади эшләр кабул ителми;

**6. Сайлап алу тәртибе:**

6.1 Оештыру төркеме һәр пьесага номер бирә һәм авторлыгын күрсәтмичә Жюри әгъзаларына тапшыра;
6.2 Текстлар һәр жюри әгъзасы куйган баллар суммасы буенча бәяләнә. Шул рәвешле иң яхшы пьесалар исемлеге (лонг-лист), соңрак кыска исемлек (шорт-лист) төзелә;
6.3 Пьесалар рецензияләнми;
6.4 Татар телендәге пьесалар татар телле жюри әгъзалары тарафыннан тикшерелә;

**7. Бүләкләр:**

7.1 Җиңгән пьесалар К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театрында читкаларда (уку) катнашачак. Уку нәтиҗәсе буенча пьесаны сәхнәдә кую буенча карар кабул ителәчәк. (Куелган очракта автор белән тиешле килешү төзелә);
7.2 Уку нәтиҗәсендә кабул ителгән пьеса К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театрында куелачак.
7.3 Иң яхшы пьесалар яки аларның өзекләре «Идел» журналында басылачак;
7.4 Финалистларга диплом тапшырылачак;
7.5 Оештыручылар махсус бүләкләр булдыру хокукын үзләрендә калдыралар;
7.6 Җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театрында узачак (Татарстан, Казан, Горький ур., 13);
7.7 Оештыручылар конкурста бүләкләү тантанасы һәм театр укулары (читка) уздырылган көннәрдә катнашучыларның юл һәм яшәү белән бәйле финанс чыгымнарын тәэмин итми.

**8. Авторлык хокукы:**

8.1 Пьесаларга барлык хокуклар авторларның үзләрендә кала;
8.2 Оештыручылар һәм Экспертлар советы әгъзалары әсәрләрне театрда куелу өчен тәкъдим итү хокукын үзләрендә калдыра;
8.3 Конкурстан тыш пьесаларны коммерцияле куллану өчен автор белән махсус килешү таләп ителә.

**9. Бәйгенең жюри составы:**

9.1 Жюрига компетентлы белгечләр: режиссерлар, әдәби бүлек мөдирләре кирә.

9.2 Жюри әгъзалары бәйгедә катнашырга хокуклы түгел.
9.3 Җиңүчеләр жюри әгъзалары утырышында үткәрелгән тавыш бирү юлы аша билгеләнә.
9.4 «Язга хәтле яз» бәйгесенең жюри әгъзалары:
Жюри составы:
Туфан Имаметдинов — К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрының баш режиссеры;
Рәмзия Галимова — «Идел» журналының баш мөхәррире;
Илфак Хафизов – Татарстанның атказанган артисты, К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры актеры;
Зөлфәт Закиров – Татарстанның атказанган артисты, К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры актеры;
Илнур Гарифуллин — К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры режиссеры;
Камил Гатауллин — К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры режиссеры;
Гөлназ Бәдртдинова — К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрының әдәби бүлек мөдире.
**10. Үткәрү вакыты:**
10.1 Гаризалар 2023 елның 1 декабреннән 15 декабренә кадәр кабул ителә.
10.2 Укыту программасы 2023 елның 20 декабрендә узачак.
10.3 Әзер эшләрне кабул итү 2024 елның 15 мартына кадәр.
10.4 Озын исемлек (лонг-лист) 30 мартка кадәр билгеле була;
10.5 Кыска исемлек (шорт-лист) 15 апрельгә кадәр игълан ителә;
10.5 Җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы 30 апрельдә үткәрелә.
**11. Бәйгенең үткәрелү тәртибе**
11.1 Бәйге турында белдерү ТР Мәдәният министрлыгы, К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры, «Идел» журналы порталларында урнаштырыла;
11.2 Пьесалар tinchurinteatr1933@gmail.com һәм Idel-kazan@mail.ru электрон почтасы аша кабул ителә;
**12. Нәтиҗәләрне ачыклау:**
12.1 Оештыручылар нәтиҗәләрне җиңүчеләргә турыдан-туры хәбәр итә;
12.2 Җиңүчеләр исемлеге К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры, «Идел» журналы порталларында урнаштырыла.

Конкурсның электрон адресы: tinchurinteatr1933@gmail.com һәм Idel-kazan@mail.ru